ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# "Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында" Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 19 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

"Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында" 2006 елның 20 июнендәге 42-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 1 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 6 (I өлеш); 2012, № 3, № 7 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) өченче абзацта "республика максатчан программаларын" сүзләрен "Татарстан Республикасының дәүләт программаларын" сүзләренә алмаштырырга;
2) сигезенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;
3) унбишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"эчәр сулар һәм хуҗалык-көнкүреш сулары белән тәэмин итү чыганакларын санитар саклау зоналарын билгеләү, үзгәртү, аларның булуын туктату турында карарлар кабул итү.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 22 декабрь
№ 112-ТРЗ